ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.05.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1264**

Муниципаль мөлкәтне сату буенча
аукцион уздыру турында

2017 елның 6 мартындагы «2017 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 175 номерлы карары нигезендә,2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Катнашучылар составы һәм хакы турында тәкъдимнәр бирү формасы буенча, Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен (алга таба – Мөлкәт) сату буенча ачык аукцион үткәрергә, әлеге карарга кушымта нигезендә.
2. Мөлкәтнең башлангыч хакын, гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, бәяләүченең 2017 елның30 мартындагы 4832-317 номерлы хисабы нигезендә расларга.
3. Задатканың күләме 20 (егерме) % һәм хакының арту күләме (аукцион адымы) лотның башлангыч бәясеннән 5 (биш) % (НДСны исәпкә алмыйча) дип билгеләргә
4. Аукцион үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүматны «Интернет» челтәрендә «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең www.zelendolsk.tatarstan.ru рәсми сайтында  һәм Россия Федерациясенең www.torgi.gov.ru. рәсми сайтында сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
______________ №______________
кушымта

Ачык аукционда сату ысулы белән хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт исемлеге

| № т/б | Мөлкәт исеме | Адресы | Мәйданы (кв.м) | Башлангыч бәясе - НДСтан башка базар хакы сумнарда (2017 елның 30 мартындагы 4832-317 номерлы хисап) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче катта урнашкан 1000 торак булмаган бина 16:49:010204:925 кадастр номерылы | Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Комсомол ур., 1 нче йорт | 38,1 | 1 199 300 |